**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Советская, д.117, г.Нурлат, 423040

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 117нче йорт, Нурлат шәһәре, 423040

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01.02.2023

КАРАР
№ 96

2023 елга "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре" муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән Исемлеге бәясенең чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы карары нигезендә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1нче һәм 2нче кушымта нигезендә 7793,48 сум (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «2022 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең иң чик күләмен раслау турында» 13.03.2022 ел, № 3 Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районы территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче З.Р. Сәйфетдинова

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 1 февралендәге
96 номерлы карарына 1 нче
кушымта

2023 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең иң чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2600,00 |
| 3 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1500,00 |
| 4 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3693,48 |
| | Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 1 февралендәге
96 номерлы карарына 2 нче
кушымта

2023 елга «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең иң чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1200,00 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1400,00 |
| 4 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1500,00 |
| 5 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3693,48 |
| | Барлыгы | 7793,48 |